ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Исәнбай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**30 октябрь 2024ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның "30" октябендә 10 сәгать 00 минутта, 2024 елның "30" октябрендә 11 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплы җыеннары нәтиҗәләре белән, түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены протоколы төзелде: Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган затлардан тыш, 2025 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчасын кертүгә һәм куллануга ризамы?, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгәннәрне, ирекле булганнарны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, тормыш иптәшләрен, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итергә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрергә:

1. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү өчен билгеләнгән һәм электр энергиясе җиһазларын ремонтлау:

1.1 энергияне саклый торган фонарьлар, лампалар һәм урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу һәм алыштыру, электрикка хезмәт килешүе буенча эш хакы түләү һәм урамнарны яктырту буенча башка чыгымнар.

2. Су белән тәэмин итү һәм су системаларын, су башняларын, скважиналарны су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировканы һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау:

2.1 сантехник материаллар сатып алу һәм җирлекне су белән тәэмин итү (тирәнлек насослар сатып алу һәм ремонтлау, суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм башка чыгымнары).

3. Торак пункт территориясен төзекләндерү:

3.1 Исәнбай авылында рөхсәтсез чүплекләрне бетерү өчен дизель ягулыгы, дизель мае һәм трактор запас өлешләрен тоту, хезмәт күрсәтү һәм сатып алу, чүп

үләннәрен чабу, тракторчының килешүе буенча эш хакы түләү, Исәнбай авылы урамнарын кардан чистарту һәм төзекләндерү буенча башка чыгымнар .

4. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:

4.1 Исәнбай авылында Совет, Октябрь, Яшьләр, Кирпеч урамнары, Совет һәм Ленин урамнары арасындагы 2 тыкрыкка вак таш сатып алу һәм юл салу өчен өлешчә ремонт ясау.

5. Гореф-гадәт буенча күмү урыннарын тәртиптә тоту, төзекләндерү, коймаларын төзек тоту:

5.1 Элмә такталарны ремонтлау һәм урнаштыру, гореф- гадәт буенча күмү урыннарын төзекләндерү һәм тәртиптә тоту, башка чыгымнар.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 550 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 296 кеше, бу 53,8 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 296 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. “2025 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекле киткәннәр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәүче ата-аналары, хатыннары, балигъ булган балаларыннан) тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 700 сум күләмендә үзара салым акчалары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1.Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:

1.1 энергияне саклый торган фонарьлар, лампалар һәм урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу һәм алыштыру, электрикка хезмәт килешүе буенча эш хакы түләү һәм урамнарны яктырту буенча башка чыгымнар.

2. Су белән тәэмин итү һәм су системаларын, су башняларын, скважиналарны су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны,

транспортировканы һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау:

2.1 сантехник материаллар сатып алу һәм җирлекне су белән тәэмин итү (тирәнлек насослар сатып алу һәм ремонтлау, суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм башка чыгымнары).

3. Торак пункт территориясен төзекләндерү:

3.1 Исәнбай авылында рөхсәтсез чүплекләрне бетерү өчен дизель ягулыгы, дизель мае һәм трактор запас өлешләрен тоту, хезмәт күрсәтү һәм сатып алу, чүп үләннәрен чабу, тракторчының килешүе буенча эш хакы түләү, Исәнбай авылы урамнарын кардан чистарту һәм төзекләндерү буенча башка чыгымнар.

3.2 кешеләрнең гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч янаучы авария хәлендәге һәм корыган яшел үсентеләрне бетерү (кисү);

3.3 керү һәм чыгу аншлагларын яңарту һәм ремонтлау;

3.4 сәүдә мәйданчыгын төзекләндерү һәм төзелеш материаллары сатып алу(базар);

3.5 үлән чабу өчен бензопила һәм триммер сатып алу.

4.Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:

4.1 Исәнбай авылында Совет, Октябрь, Яшьләр, Кирпеч урамнары, Совет һәм Ленин урамнары арасындагы 2 тыкрыкка вак таш сатып алу һәм юл салу өчен өлешчә ремонт ясау, урамнарны кардан чистарту.

5. Гореф-гадәт буенча күмү урыннарын тәртиптә тоту, төзекләндерү, коймаларын төзек тоту:

5.1 Элмә такталарны ремонтлау һәм урнаштыру, гореф- гадәт буенча күмү урыннарын төзекләндерү һәм тәртиптә тоту, башка чыгымнар.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Мухаммадиев